Итоговая контрольная работа по литературному чтению
на родном (татарском) языке
2 класс

Ф.И. учащегося________________________________________________

1. Текстны укы.

Яңа көрәк

Әнвәрнең әнисе, ике зур кәрзин күтәреп, базардан кайтып керде. Шыплап тутырылган кәрзиннәрне күрүгә, Әнвәр әнисенең каршына йөгерде. Тәмле-тәмле нәрсәләр алып кайтканын белә иде инде ул аның.

- Яле, улым, әйтеп җибәр әле, бу кемгә? – диде аңа әнисе, кәрзиннәрнең берсенннән эре-эре, бик матур кызыл алмалар чыгарып.
- Миңа! – диде Әнвәр һәм әнисенең кулыннан ялт иттереп тартып та алды.
- Ә бусын кемгә бирик икән?
  Әнисе кулына кечерәк кенә катыргы тартмага салынган аллы-гөлле торт күтәреп тора иде. Үзе һаман, елмаеп, Әнвәргә карый.
- Бусы да миңа! – диде Әнвәр, шатырдатып алмасын тешли-тешли.
- Ә бусы?!
  Күр инде, әнисенең кулында – яңа пешкән җир җиләкләре! Менә бу яңалык, ичмаса! Пешеп тә өлгергәннәрме икәнни?
  Әнвәр беравык, кулындагы алмасын тешләргә дә онытып, кызарышып, тулып пешкән җиләкләргә исе китеп карап торды.
- Я, бусы кемгә инде, ник дәшмисең? – диде әнисе.
- Ә бусымы? Бусы миңа да миңа инде аның! – диде Әнвәр, юеш иреннәрен җәеп елмая-елмая һәм, җиләкләр салынган кечкенә генә кәрзинне эләктереп китә дә башлады.
- Тукта әле, тукта! Бетмәде бит әле, - диде әнисе һәм, ничектер Әнвәргә серле генә карап, әлеге олы кәрзиннән өр-яңа, ялтырап торган бер көрәк чыгарды.
- Менә тутыкмый торган көрәк бу. Үзе җиңел генә, үзе үткен, тик саплап кына җибәрәсем бар. Бусы кемгә була инде? – дип сорады әнисе, нигәдер бу юлы бик җитди карап.

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 15:21:44 МСК
Идентификатор документа d70c0e11-fe06-4d9e-8aba-96473ab571ef

Әнвәр бер кулына – алма, икенчесенә җиләкләр тоткан килеш, әле көрәккә, әле кулындагы җимешләргә карап-карап торды да кинәт катгый бер карарга килеп:

- Ә-ә, һаман-һаман миңа гына ярамас. Алай дөрес түгел ул. Бусы инде әти белән сиңа булсын... – диде.

Әнисенең йөзеннән елмаю югалды. Шунда ук аяклары арыганлыгы исенә төште, ахры. Ул, күңелсезләнеп кенә урындыкка барып утырды да, авыр сулап, Әнвәрнең күзләренә текәлде

Нигә икән? (Р.Вәлиева)

2. Бу әсәр кайсы төргә керә?

а) хикәя б) мәсәл

ә) шигырь в) әкият

3.Малайның исемен яз____________________

4. Әнвәрнең әнисе кайдан кайтып керде?________________

5. Кәрзиндә нәрсәләр була? _______________________________________

6. Текст эчтәлегенә туры килгән (подходит) җөмләне билгелә.

а) Әнвәр көрәк тотып кар көрәргә чыгып китте.

ә) Әнвәргә әтисе бик матур көрәк алып кайтты.

б) Әнвәр әнисе каршына йөгерде.

7. Әсәрдән алынган җөмләләрне дөрес эзлеклелектә урнаштыр.

а) Бусы инде әти белән сиңа булсын.

ә) Әнисенең йөзеннән елмаю югалды.

б) Тукта әле, тукта! Бетмәде бит әле.

в) Яле, улым, әйтеп җибәр әле, бу кемгә? ______________

8.”Кәҗә белән сарык ”-әкиятен кем язган

-Г.Тукай

-М.Җәлил

Ф.Яруллин

9. .Хайваннар турындагы әкиятләрнең төп геройлары:

а)Кешеләр ; ә)кошлар ; б)хайваннар.

10.Татар халкының “Өч кыз” әкиятендә игелекле бала ...

а) кече кыз б) уртанчы кыз в) олы кыз г) берсе дә түгел

**<u>Бәяләү:</u>**

*– 1 – 10 нчы биремнәр барысы дөрес булса, “5’’ле куела;*

*– 7 - 8 бирем җаваплары дөрес булса, “4’’ле куела;*

*– 5 - 4 – биремгә дөрес җавап өчен, “3’’ле куела;*

*Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап,сәнгатьле һәм аңалешлы итеп уку да билгегә балл өсти.*

## <u>Арадаш аттестация өчен биремнәр. 2сыйныф әдәби уку</u>

**2 вариант**

1. **<u>1. Текстны игътибар белән тулысынча укып чык.</u>**

**Дельфин да күрмәгән.**

Сез Алмазны күрдегезме? –

Кайткан диңгез буеннан.

Ул кабырчык җыйган анда

Һәм көнозын коенган.

Коенган ул иртән, көндез,

Коенган ул кичен дә.

Кыскасы, бер ай буена

Яткан ул су эчендә.

Ләкин ул диңгез эченә.

Ахры, бер дә кермәгән:

Диңгездә бер ай ял итеп,

Бер дельфин да күрмәгән.

Диңгез буйлары матурдыр,

Анысын аңлыйм да мин.

Тик бер дельфин да күрмәсәм,

Диңгезгә бармыйм да мин!

**2.Сорауларга җавап бир**

1.Бу әсәр :

-шигырь

-хикәя

-әкият

3**.Малайның исемен яз**______________________

4.**Төп герой кайда барга**н ___________________

4.**Малай никадәр су эчендә яткан**______________

5**.Малай нәрсәләр җыеп кайткан**__________________

6.**Дельфин турында бер-ике җөмлә яз**

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________

7.**Диңгездә тагын нинди балыклар яши**________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________-

8**.”Кәҗә белән сарык ”-әкиятен кем язган**

-Г.Тукай

-М.Җәлил

Ф.Яруллин

9**. .Хайваннар турындагы әкиятләрнең төп геройлары**:

а)Кешеләр ; ә)кошлар ; б)хайваннар.

10.**Татар халкының “Өч кыз” әкиятендә игелекле бала ...**

а) кече кыз б) уртанчы кыз в) олы кыз г) берсе дә түгел

**Бәяләү:**

*– 1 – 10 нчы биремнәр барысы дөрес булса, “5”ле куела;*

*– 7 - 8 бирем җаваплары дөрес булса, “4”ле куела;*

*– 5 - 4 – биремгә дөрес җавап өчен, “3”ле куела;*

*Тәкъдим ителгән текстның эчтәлеген тулаем аңлап,сәнгатьле һәм аңалешлы итеп уку да билгегә балл өсти.*

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 15:20:33 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 15:21:44 МСК
Идентификатор документа d70c0e11-fe06-4d9e-8aba-96473ab571ef